ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
БИЛГЕЛӘМӘСЕ

«Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» 2010 елның 3 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 3 өлеше һәм 9 статьясындагы 3 өлеше белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында

Казан шәһәре 2018 елның 13 июле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында судья Э.М. Мостафина мәгълүматын тыңлаганнан соң

ачыклады:

1. Татарстан Республикасы Конституция судына хокуктан файдалануга сәләтсез гражданка Г.М. Сабитова мәнфәгатьләрендә эш итүче гражданка Ә.Ф. Сабитова «Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» 2010 елның 3 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 3 өлеше һәм 9 статьясындагы 3 өлеше белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

2018 елның 9 июлендә, гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаяте Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы тарафыннан алдан өйрәнү стадиясендә булганда, Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.М. Сабитованың вафат булуы турында мәгълүмат килде (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты ГХАТ бүлегенең 2018 елның 22 июнендәге 173 номерлы үлү турында акт язмасы).

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 63 статьясы нигезендә әгәр утырыш барышында мөрәҗәгатьне карауга кабул итүдән баш тартырлык сәбәпләр килеп чыкса, Татарстан Республикасы Конституция суды эш алып баруны туктата.

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты нигезендә опекага алынучы үлгән очракта опека туктатыла. Опекага алынучының вафаты опекуны шикаятен карауга алудан баш тартуга һичшиксез нигез булып торганга күрә, гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаяте буенча эш башкару туктатылырга тиеш.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 63 статьясына һәм 73 статьясындагы беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. «Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» 2010 елның 3 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 3 өлеше һәм 9 статьясындагы 3 өлеше белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата гражданка Ә.Ф. Сабитова шикаяте буенча эш башкаруны, мөрәҗәгать итүче аның мәнфәгатьләрендә эш иткән затның вафаты сәбәпле, туктатырга.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Ә.Ф. Сабитовага җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 17-О

Татарстан Республикасы Конституция суды